# Сыйныфтан тыш уку дәресе.
# «Чәчәкләр. Муса Җәлил.»



# МАКСАТ:

1) Муса Җәлилнең тормышы
һәм иҗаты белән танышу;
2) Муса Җәлилнең“Чәчәкләр
шигырен анализлау;
3) Муса Җәлилнең батырлыгы
үрнәгендә
батырлык, патриотизм, дуслык
хисләре тәрбияләү.

# 1941 елның 22 июнендә – Бөек Ватан сугышы башлана



# Сугыш 1418 көнгә сузыла.



# Муса Җәлил әнисе һәм апасы белән



# Муса Җәлил кызы Чулпан белән







Муса Җәлил хөкем алдыннан.(1944г.)

## Чәчәкләр.

**Муса Җәлил.**

Барыгыз болынга, балалар!
Йөгерегез, уйнагыз, көлегез!
Елмайсын күреп шат аналар,
Юансын боеккан күңелегез.

Болында күп матур чәчәкләр,
Барсы да татлы хуш иследәр.
Нәркисләр, сөмбелләр һәм мәкләр,
Нәкъ сезнең ирнегез төсләләр.

Җил көйләп тирбәтә аларны,
Иркәли кояшның нурлары.
Алар бит изге Җир – ананың
Сөекле кызлары, уллары.

Бу җирдә күп булды сугышлар,
Янгыннар, явымнар, давыллар,
Киселде күп батыр тормышлар,
Янды зур калалар, авыллар.

Ил өчен барды бу зур көрәш,
Давыллы, дарылы елларда.
Сеңде бу туфракка күпме яшь,
Күпме кан тамды бу кырларга.

Шул каннар һәм яшьләр аркылы,
Ил бөек җиңүгә иреште.
Яз килде; дулкынлы, ялкынлы
Чәчәккә төренде җир өсте.

Бу гөлләр шытты Җир-ананың
Яралы йөрәге түрендә.
Ничек ул йөрәкнең янганын
Мин күрәм аның һәр гөлендә.

Җыегыз, балалар, сез җирнең
Бу нәфис һәм иркә гөлләрен.
Китрегез данлыклы хөр илнең,
Тәбрикләп, шатлыклы көннәрен.

Сезнең дә, бәлки, бу сугышта
Үлгәндер атагыз, анагыз.
Хәтерләп сезне соң сулышта…
Һәм бардыр йөрәктә ярагыз.

Сез назлап үбегез гөлләрне,
Хуш истән күңлегез ачылсын.
Җир бирде сезгә шат көннәрне,
Йотып тир, кан һәм яшь тамчысын.

Балалар, сез гөлләр үзегез,
Чыктыгыз калкып җир карныннан.
Һәм чәчәк аттыгыз, үстегез
Атагыз, агагыз каныннан.

Сез безгә шулкадәр кадерле,
Шулкадәр ягымлы, сөйкемле!
Ал таңы алдагы дәвернең
Йөзегездә чагладыр шикелле.

Чәчәкләр, үсегез, чәчәкләр,
Дәрт биреп безнең шат күңелгә.
Сезгә бу шатлыклар, рәхәтләр
Бит җиңеп алынган гомергә.

# 1945 елның 9 Май көне – Бөек Җиңү бәйрәме



# Муса Җәлил һәйкәле



# Муса Җәлилгә Оренбургта куелган һәйкәл




Памятник поэту Мусе Джалилю г.Оренбург

© Geo Anton / Фотобанк Лори
ФОТОБАНК ЛОРИ
lori.ru/202311

# Муса Җәлилнең тормыш иптәше Әминә һәм кызы Чулпан укучылар белән очрашу вакытында




Без сугыш
теләмибез